# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

## КАРАР № 24

III чакырылыш XXVII утырыш Урыссу ш.т.б. 2019 елның «26» августы

*Хезмәт (вазифа) урынында үз-үзеңне тотуга таләпләр һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында комиссия хакында Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында*

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.“Комиссия төзү тәртибе” дип аталган 2 бүлекнең 2.1 пункчасының беренче абзацын кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия составы Ютазы муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.».

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелганнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, регламент һәм җирлек Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

*Ютазы муниципаль район Башлыгы –*

*Ютазы район советы Рәисе* *Р.М. Нуриев*